РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

Буа шәһәре

КАРАР

31 март 2026 ел

№ 3-9

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 3-21 номерлы
«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында,
шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл
хуҗалыгында муниципаль контроль турында
нигезләмәне раслау хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 08 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы, 2020 елның 31 июлендәге  248-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон ,  «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы  нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 3-21 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» карарына  түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1.3 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әгәр контроль (күзәтчелек) органы карамагында булган белешмәләр һәм документлар җитәрлек булмаса, документлар буенча тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләр башкарылырга мөмкин:»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында  http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырып чыгарырга, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа

муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын үтәүче И.Ф.Еремеев